**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮРӘЗМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXXI УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 49**

Үрәзмәт авылы "16"май 2023 ел

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның барсы да мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең- физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. Әлеге карарны Үрәзмәт авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда, Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге сайтында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәм "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үзенең гамәлен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Үрәзмәт авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Закирҗанов